ГЛАВА МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_10.01.2022_ Мөслим № 1_

**Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарында хезмәт стажын билгеләү һәм хезмәт хакына өстәмә түләү билгеләү буенча комиссия төзү турында**

Мөслим муниципаль районының норматив-хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү һәм Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен хезмәт хакына айлык өстәмә түләү билгеләү максатыннан чыгып:

1. Мөслим муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт стажын билгеләү һәм вазыйфаи окладына өстәмә түләү билгеләү комиссиясе составын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

2. Мөслим муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт стажын билгеләү һәм вазыйфаи окладына өстәмә түләү билгеләү буенча комиссия турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Г. Гариповка йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы**
**урынбасары** **А.М. Әхмәтҗанов**

Муниципаль район Башлыгының
2022 елның « 10 » 01
1 номерлы боерыгына
1 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт стажын билгеләү һәм вазыйфаи окладына өстәмә түләү билгеләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хуҗин А.Р. | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, **комиссия рәисе;** |
| Бубекова Н.А. | Муниципаль районның финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча), **рәис урынбасары** |
| Әхмәдуллина Л.В. | Муниципаль район Башкарма комитетының кадрлар бүлеге башлыгы, **комиссия секретаре.** |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Гарипов Р.Г. | Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хантимеров Р.Ф. | Муниципаль район Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |

Муниципаль район Башлыгының
2022 елның « 10 » 01
1 номерлы боерыгына
2 нче кушымта

**Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт стажын билгеләү һәм вазыйфаи окладына өстәмә түләү билгеләү буенча комиссия турындагы нигезләмә**

1. Муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык вазыйфаи окладка өстәмә түләү өчен муниципаль хезмәт стажы Мөслим муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе (алга таба – комиссия) тарафыннан билгеләнә.

Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

Комиссия Мөслим муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт стажын билгеләү мәсьәләләрен карый.

Муниципаль район комиссиясе составы муниципаль район Башлыгы тарафыннан раслана.

Муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү алу хокукын бирә торган хезмәт стажын билгеләү өчен документлар булып түбәндәгеләр тора:

а) хезмәт кенәгәсе;

б) хезмәт кенәгәсе булмаганда, шулай ук хезмәт кенәгәсендә дөрес булмаган яисә төгәл булмаган язмалар булган йә эшчәнлекнең аерым чорлары турында язмалар булмаган очракларда – хезмәт (эш) урыныннан, архив учреждениеләреннән белешмәләр, хезмәт стажын раслый торган приказлардан һәм башка документлардан өземтәләр;

в) хәрби билет яки хәрби комиссариатларның хәрби хезмәт стажын раслаучы белешмәләре.

2. Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажына муниципаль хезмәт вазыйфаларында, сайланулы муниципаль вазыйфаларда һәм дәүләт вазыйфаларында эшләү вакыты кертелә.

Муниципаль хезмәт стажына хезмәт эшчәнлегенең башка чорларын кертү федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажы дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте стажына тиңләштерелә.

3. Муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладыннан чыгып, өстәмә түләүләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алмыйча исәпләнә.

Муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә әлеге өстәмә күләмен билгеләү яки үзгәртү хокукы барлыкка килгән көннән билгеләнә һәм түләнә.

Мөслим муниципаль районының тиешле җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәттәге тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә күләмен билгеләү яки үзгәртү хокукы бурычларны үтәү чорында, яңадан һөнәри әзерләү яки уку учреждениесендә эштән аерылып квалификация күтәргәндә, һәм башка шундый ук очракларда, әгәр хезмәткәр тарафыннан уртача хезмәт хакы саклана икән, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең еллык түләүле отпускта булу чорында, аның вакытлыча эшкә яраксызлыгы чорында туры килсә, аңа әлеге хокук барлыкка килгәннән соң күрсәтелгән өстәмә түләү билгеләнә һәм акча эчтәлеге яңадан исәпләү башкарыла.

4.Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү өчен муниципаль хезмәт стажын исәпләү түбәндәге очракларда башкарыла:

а) граждан муниципаль хезмәткә кергәндә һәм сайланулы муниципаль вазыйфаларны биләгәндә, ләкин вазыйфага билгеләнгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча, Хезмәт (эш)чорын раслаучы өстәмә документлар тапшыруны таләп итә торган очраклардан тыш;

б) муниципаль хезмәтнең тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүне яңадан исәпләү өчен гамәлдәге законнарда билгеләнгән һәр чираттагы чоры җиткәндә.

5. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда хәлиткеч тавыш бирү хокукы комиссия рәисе тарафыннан бирелә. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмә нигезендә ай саен өстәмә түләү билгеләү турында боерык чыгарыла. Әлеге күрсәтмә муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү билгеләү өчен нигез булып тора.

Күрсәтмәнең бер күчермәсе муниципаль районның үзәкләштерелгән бухгалтериясенә тапшырыла, боерыкның икенче күчермәсе (яки күрсәтмәдән өземтә) хезмәткәрнең шәхси эшенә кертелә.

Муниципаль хезмәткәрне эштән азат иткәндә муниципаль хезмәттәге тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм аны түләү ахыргы исәпләгәндә башкарыла.